КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 1181

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү чыгымнарын финанслау тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү чыгымнарын финанслау тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособиегә акча күздә тотарга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.
4. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 20 декабрь, 1181 нче
карары белән расланды

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү чыгымнарын финанслау тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән билгеләнгән 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие (алга таба – пособие, пособие алучылар) бирү чыгымнарын финанслау механизмын билгели.

2. Пособие түләү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга күздә тотыла торган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) ай саен, агымдагы айның сигезенә кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына пособие бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә заявка (алга таба – заявка) җибәрә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы ай саен Министрлыкка аның заявкалары буенча финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерә.

5. Министрлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанслануның иң чик күләмнәре җиткерелгәннән соң, ай саен биш эш көне эчендә, пособие алучыларның банкта яки башка кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына алга таба күчерү өчен акчаны «АЦК-Финанслар» системасында эш итү характерындагы заявка рәвешендә электрон төрдә «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – Үзәк) күчерүне гамәлгә ашыра.

6. Үзәк ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 10ысыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка, пособие алучылар санын күрсәтеп, Татарстан Республикасы бюджетыннан башкарылган чыгымнар турында мәгълүмат кертә.

7. Министрлык ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, пособие алучылар санын күрсәтеп, Татарстан Республикасы бюджетыннан башкарылган чыгымнар турында мәгълүмат бирә.

8. Министрлык һәм Үзәк бирелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм акчаны максатчан файдаланмау өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җавап бирә.

9. Бу Тәртип нигезендә бирелгән акчаны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

_______________